**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.08.2018 № 684

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 22 маендагы 535 санлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы территориясендәге җирләрне файдалануны контрольдә тоту һәм җир законнарын бозуларны профилактикалау” муниципаль функциясен үтәү буенча административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

“Дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында” 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәте “Запрос җибәрү һәм тикшерү оештыру һәм үткәрү вакытында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроле органнары тарафыннан башка дәүләт органнары, җирле узидарә органнары яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынган оешмалар карамагында булган документлар һәм (яки) мәгълүмат, шулай ук электрон формада, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында түләүсез нигездә алу турында” 2016 елның 18 апрелендәге 323 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәте “Тикшерү оештыру һәм үткәрү вакытында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроле органнары тарафыннан соралган һәм алынган башка дәүләт органнары, җирле узидарә органнары яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынган оешмалар карамагында булган документлар һәм (яки) мәгълүмат исемлеген раслау турында” 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы

боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 22 маендагы 535 санлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы территориясендәге җирләрне файдалануны контрольдә тоту һәм җир законнарын бозуларны профилактикалау” муниципаль функциясен үтәү буенча административ регламентына түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. 2.5.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

Тикшерү оештыру һәм үткәрү вакытында Палатаның вазифаи затлары түләүсез нигездә Россия Федерациясе Хөкүмәте 323 номерлы карары белн расланган срокларда һәм тәртибендә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Россия Федерациясе хөкүмәте 724-р номерлы боерыгы белән расланган исемлеккә кертелгән башка дәүләт органнары, җирле узидарә органнары яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынган оешмалар карамагында булган, шулай ук электрон формада, документлар һәм (яки) мәгълүмат сорап алалар.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында түбәндәге документалр сорап алына:

- Бердәм дәүләт кучемсез милек реестрыннан кучемсез милек турында күчермә;

- Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан мәгълүматлар (юридик затлар өчен);

- Бердәм дәүләт индивидуаль эшкуарлар реестрыннан мәгълүматлар (индивидуаль эшкуарлар өчен).”.

2. Әлеге карарны мәгълүмат-телекоммуникация “Интернет” челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

Җитәкче Р.В. Михеев